**Бәхетемнең ачкычы**

1. Бәхетемнең ачкычы
Синдә булган бит җаным.
Бүләк иттең син миңа
Дөньяның бар шатлыгын.

Кушымта:
Күгем аяз, күң(е)лем гел наз
Син булгач яннарымда.
Сүнмәс моңым, шатлык җырым
Син минем тормышымда.

2.Онытылды синең белән
Үткәннәрнең бураны.
Һәр яңа көн туган саен,
Тоям йөрәк җылыңны.

3.Ышыклыйсың җил-яңгырдан,
Булып гел ныклы терәк.
Мәңге бәхетле булырга,
Минем бары шул теләк.